РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Аксубаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль
районы башкарма
комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

« 30 » 03 2020

№ 227

Аксубаево

Аксубай муниципаль районы территориясендә
продукция сатуга чикләүләр кертү турында

Гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау, шулай ук район территориясендә яңа коронавирус инфекциясе таралуны минимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 нче номерлы карарына, 2020 елның 18 мартындагы 6 нче номерлы Санитария-эпидемиягә каршы комиссиясе карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Киләсе көннең 22.00 сәгатьтән 7.00 сәгатькә кадәр Аксубай муниципаль районы территориясендә товарларны ваклап сатучы оешмалар, шәхси эшмәкәрләр, башка затлар тарафыннан 2020 елның 30 мартыннан алып эпидемиологик хәлнең тотрыклануына кадәрге чорда сатуны тыярга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http:// Aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм милек белән идарә итү буенча беренче урынбасары И.И. Моратшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф.Горбунов